РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 ел 25 нче июль** **Чистай шәһәре** **№ 45/1**

Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына таянып, Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 85-87 статьяларына нигезләнеп, Чистай муниципаль районы Советы

**Карар бирә:**

1. Чистай муниципаль районы Советының 2014 елның 29 гыйнварында кабул ителгән 32/1 номерлы карары (Чистай муниципаль районы Советының 2015 елның 28 апрелендәге 45/1, 2015 елның 18 декаберндәге №3/4, 2017 елның 10 февралендәге №17/2, 2017 елның 7 нче августындагы №23/1, 2018 елның 29 мартындагы №32/1, 2018 елның 23 ноябрендәге №39/1 номерлы карарлары редакциясендә) белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасында “хокуклар” сүзеннән соң “аз санлы төп халыклар һәм башкалар” сүзләрен өстәргә;

1.2. 42 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасының унике абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 46 статьяның 6 пунктында “район башлыгы белән килешү буенча” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Татарстан Республикасының “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларында – «Чистопольские известия» (“Чистай хәбәрләре”) газетасында һәм дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы **Д.А. Иванов**